**Татар мәктәпләрендә татар әдәбиятыннан төп гомуми белем мәктәп курсы өчен үрнәк билетлар**

**Примерные билеты по татарской литературе за курс основной школы для татарских школ**

## Аңлатма язуы

2011-2012 нче уку елында IX сыйныфны тәмамлаучыларга шул сыйныфка мөнәсәбәтле һәм укучы үзе сайлап алган теләсә кайсы фәннән телдән имтихан тапшыру рөхсәт ителә. Укучылар тарафыннан сайланган имтиханнар яңа һәм традицион формада уздырыла.

Татар әдәбиятыннан телдән имтиханны төрле формаларда оештырырга мөмкин (**әңгәмә, реферат яклау, билетлар нигезендә имтихан тапшыру**).

**Әңгәмә** билгеле бер темага нигезләнеп (ул тема укучыга алдан ук билгеле була), әзерлексез төстә генә укучының киңәйтелгән җавабын тыңлау формасында оештырыла. Мондый форманы татар әдәбияты фәнен яхшы белгән укучыларга тәкъдим итү уңышлы, чөнки ул укучы һәм имтихан алучы укытучының үзара әңгәмәсенә корыла, ә укытучы моңа кадәр үтелгән әдәбият курсына мөнәсәбәтле теләсә нинди сорау аша укучының белем дәрәҗәсен ачыклый ала.

Имтиханны **реферат яклау** формасында тапшыру мөстәкыйль фикер йөртергә һәм язма эш башкарырга сәләтле укучылар өчен отышлы. Уку елының икенче яртысы башлануга укучы укытучысы белән билгеле бер теманы сайлап ала һәм аңа кагылышлы тәнкыйди, фәнни-методик, әдәби материалны туплый. Рефератта өйрәнү объекты, аның асылы төгәл билгеләнергә, төп нәтиҗәләр чыгарылырга, әдәбият исемлеге тәкъдим ителергә тиеш. Бу очракта имтиханга бер атна кала танышып һәм бәяләп чыгу өчен реферат укытучыга тапшырыла. Имтихан вакытында комиссия рецензия белән таныша һәм укучы тарафыннан хезмәт яклангannan соң билге куела.

Имтиханны **билетлар** ярдәмендә тапшыру иң отышлы һәм киң таралган форма буларак билгеле. Татар мәктәпләрендә татар әдәбиятыннан имтиханны традицион формада уздыру өчен үрнәк билетлар “Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары”на (К:. Мәгариф, 2010), “Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең вакытлыча дәүләт стандартларына” (Казан, 2008) нигезләнеп төзелде.

Имтихан билетлары, нигездә, 7, 8, 9 нчы сыйныф материалларына таянып төзелде, аерым очракларда алдагы сыйныфта үтелгәннәргә дә мөрәҗәгать ителде. Татар мәктәпләрендә әдәбият дәресләре ике программага (А.Әхмәдуллин һәм А.Яхин) нигезләнеп укытыла. Имтиханга сораулар төзү барышында бу як та исәпкә алынды, ягъни ике программа өчен дә уртак әдипләр сайланды, аларның ике программада каралган әсәрләре тәкъдим ителеп, укучыга сайлап алу мөмкинлеге калдырылды.

Шул критерийлар нигезендә сораулыклар төзүнең билгеле бер системасы эшләнде. Имтихан билетларында беренче сораулар аерым бер әдип иҗатына яки билгеләнгән әдәби чорга хронологик бәя бирүне алга куя һәм укучыдан күрсәтелгән вакыт аралыгында әдәбиятның төп сыйфатларын, үсеш-үзгәреш закончалыкларын, үзенчәлекләрен аерып чыгаруны, тулы җаваплар бирүне таләп итә. Икенче сорау тәкъдим ителгән әсәргә анализ ясауга йөз тота һәм укучының әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып алуын, әдәби әсәрнең темасын, идеясен, автор күтәргән проблемаларны дөрес билгели алуын, геройга характеристика бирү мөмкинлеген тикшерү максатын алга куя. Моннан тыш сораулар укучының әдәбиятны, әсәрне аңлау дәрәҗәсен генә түгел, аңа шәхси мөнәсәбәтен белдерү, логик фикерләү дәрәҗәсен, иҗади мөмкинлекләрен, эрудициясен дә ачыкларга мөмкинлек бирә.

Имтихан өчен **2 комплект билетлар** тәкъдим ителә: аларның берсе татар мәктәпләрендә укучы татар балаларына, икенчесе рус мәктәбендә белем алучы татар укучыларына йөз тотып төзелде.

Әлеге ике комплект имтихан билетлары да үрнәк буларак тәкъдим ителә һәм мәктәпләр тарафыннан имтихан билетлары төзү барышында кулланыла ала. Укытучы аларны үзгәртү хокукына ия: сорауларның урыннарын, формулировкаларын алыштырырга яки аерым сорауларны үзгәртергә мөмкин.

Имтихан барышында укчыга **әзерлек өчен 40 минут** вакыт бирү күздә тотыла.

## Укучының җавабын билгеләүгә күрсәтмәләр

Имтиханда укучының җавабын билгеләү барышында түбәндәге критерийлар исәпкә алынырга тиеш:

- укучының сорауны аңлап, төгәл җавап бирүе;
- әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләр аңлап, урынлы куллануы;
- җавабын мисаллар ярдәмендә ныгытуы, соралган әсәрне (әсәрләр) җитәрлек күләмдә файдалануы (цитататалар китерү, әсәрләргә сылтамалар бирү һ.б.);
- җавапның нигезле, дәлилләнгән булуы;
- җавапның логик яктан эзлекле булуы, укучының үз фикерләрен үзара бәйләнештә бирүе, төгәл җиткерә алуы;
- өзекләрне сәнгатьле сөйли алуы;
- җавапның әдәби сөйләм нормаларына туры килүе.

Әгәр укучы билет сорауларына дөрес, төгәл җавап биргән һәм җавап алдагы критерийларга туры килгән очракта **«5»ле билгесе** куела.

Әгәр укучы билетның ике соравына бик яхшы җавап биреп, өченчесенә төгәл җавап булмаган яки сорауларның өчесенә җавап биреп тә, алда күрсәтелгән теге яки бу критерий үтәлмәгән очракта **«4»ле билгесе** куела.

Әгәр укучы билетның бер соравына җавап биреп, икесенә төгәл җавап булмаган яки сорауларның өчесенә өстән-өстән җавап биреп тә, алда күрсәтелгән төп таләпләр үтәлмәгән очракта **«3»ле билгесе** куела.

## Татар әдәбиятыннан имтихан билетларын төзү өчен кирәкле әдәбият исемлеге

(үрнәк)

**Борынгы татар әдәбияты**

М.Кашгарый “Диване лөгат әт-төрк”.
Й.Баласагунлы “Котадгу белек” .

**Урта гасыр татар әдәбиятыннан**

Кол Гали. “Кыйссаи Йосыф”.
“Идегәй” дастаны.
Сәйф Сараи. “Гөлстан бит-төрки”, “Сөһәил вә Гөлдерсен”.
Мөхәммәдьяр. “Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур”.
Мәүла Колый хикмәтләре.
Габдерәхим Утыз Имәни. “Гыйлемнең өстенлеге турында”, “Егет булу турында” шигырьләре, хатыны Хәмидәгә мәрсиясе.

**XIX гасыр татар әдәбиятыннан**

Муса Акъегет. “Хисаметдин менла”.
Каюм Насыйри. “Әбугалисина”.
Шәмсетдин Зәки. “Һай, нә оерсән?!”, “Бу сүзне кәгазьгә язмак кирәктер”, “Эстәсәм, галәмдә...” һ.б.
Әбелмәних Каргалый. “Мөнаҗәт”, “Сәхрада”, “Бөтен дөнья бәнем булса...”.
Заһир Бигиев. “Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә”.
Ризаэтдин Фәхретдин. “Әсма, яки Гамәл вә җәза”.
Габделҗәббар Кандалый. “Сәхибҗамал” поэмасы, шигырьләре.
Габдрахман Ильяси. “Бичара кыз”.
Фатих Халиди. “Рәдде бичара кыз”.

**XX гасыр татар әдәбиятыннан**

Габдулла Тукай. “Исемдә калганнар”, “Су анасы”, “Шүрәле”, “Сабыйга”, “Эшкә өндәү”, “Эш беткәч уйнарга ярый”, “Пар ат”, “Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш” һ.б.
Дәрдемәнд. “Җәй үтте”, “Кораб”, “Видагъ” һ.б.
Гаяз Исхакый. “Кәҗүл читек”.
Фатих Әмирхан. “Нәҗип”.

Шәриф Камал. “Акчарлаклар”.
Галимҗан Ибраһимов. “Алмачуар”.
Галиәсгар Камал. “Беренче театр”.
М.Фәйзи. “Галиябану”.
Кәрим Тинчурин. “Җилкәнсезләр”,“Американ”.
Һади Такташ. “Алсу”, “Таң кызы”, “Ак чәчәкләр”.
Муса Җәлил. “Җырларым”, “Кошчык”, “Тик булса иде ирек”, “Ышанма”, “Бер үгет” һ.б.
Ф. Кәрим. “Ант”, “ Ватаным өчен”, “Сөйләр сүзләр бик күп алар”, “Кыңгыраулы яшел гармун”, “Сибәли дә сибәли”, “Кайгы” һ.б.
Хәсән Туфан. “Кайсыгызның кулы җылы?”
Фатих Хөсни. “Йөзек кашы”.
Әмирхан Еники. “Әйтелмәгән васыять”, “Курай”, “Матурлык”.
Илдар Юзеев. “Бакчачы турында баллада”, “Йолдыз Кашка турында баллада”.

## Билет №1

1. Матур әдәбиятның кеше тормышындагы роле. “Әдәбият тарихы” төшенчәсе. Татар әдәбияты тарихының чорларга бүленеше мәсьәләсе.
2. Мирхәйдәр Фәйзинең “Галиябану” драмасы, конфликт үзенчәлеге. Хәлил белән Галиябану мәхәббәте, аның фаҗигале тәмамлануы.

## Билет №2

1. Болгар чоры әдәбияты. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасы, сюжеты, вакыйгалар. Төп геройлар язмышы.
2. Хәсән Туфанның “Кайсыгызның кулы җылы?” шигырендә лирик геройның хәсрәте хакында сөйләгез.

## Билет №3

1. Алтын Урда чоры әдәбияты, үзенчәлекләре, шул чор әдәбиятының бер вәкиле буларак Сәйф Сараи иҗаты (“Гөлстан бит-төрки”, “Сөһәил вә Гөлдерсен” әсәрләре).
2. Шәриф Камалның “Акчарлаклар” повестенда (яки “Матур туганда” романында) яңа тип геройлар.

## Билет №4

1. Казан ханлыгы чоры әдәбияты, төп авторлар, аларның иҗатларына хас

үзенчәлекләр. “Идегәй” дастанының сәнгатьчә эшләнеше.
2. Һади Такташның “Алсу” (яки “Таң кызы”) шигырьләренә анализ ясагыз.

## Билет №5

1. XVII йөз әдәбияты. Мәүла Колый хикмәтләрендә күтәрелгән мәсьәләләр.
2. Галимҗан Ибраһимовның “Алмачуар” хикәясенең сюжеты, Закир образына бәя бирегез.

## Билет №6

1. Мөхәммәдьярның тормышы, иҗаты (“Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур” поэмалары).
2. Галиәсгар Камалның “Беренче театр” комедиясендә конфликт үзенчәлеге.

## Билет №7

1. XVIII йөз әдәбияты. Г.Утыз-Имәнинең тормыш юлы, эшчәнлеге. Иҗатында гыйлем-мәгърифәт мәсьәләләре (“Гыйлемнең өстенлеге турында”, “Егет булу турында” шигырьләре, хатыны Хәмидәгә мәрсиясе).
2. Габдулла Тукайның “Исемдә калганнар” автобиографик әсәрендә авторның үз-үзенә бәясе.

## Билет №8

1. Мәгърифәтчелек чоры әдәбиятына хас үзенчәлекләр. Мәгърифәтчелек реализмы.
2. Дәрдемәнд шигырьләрендә символик образлар куллану, аларның вазифасы һәм әһәмияте. (“Җәй үтте”, “Кораб”, “Видагъ” һ.б.). Бер шигырен яттан сөйләргә (укучы үзе сайлый).

## Билет №9

1. Г.Камал иҗаты, татар драматургиясе һәм театрның формалашуына, үсешенә керткән өлеше.
2. Һади Такташның “Ак чәчәкләр” шигырендә ак чәчәкләр метафорасына салынган мәгънәне ачыклагыз.

## Билет №10

1. Язучы, мәгърифәтче, тәрҗемәче буларак Каюм Насыйри эшчәнлеге.

2. Гаяз Исхакыйның “Кәҗүл читек” хикәясендә Әхмәдулланың кәҗүл читек белән бәйләнешле кичерешләренә бәя бирегез.

## Билет №11

1. Заһир Бигиевнең тормыш юлы, иҗаты (“Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә” романы).
2. Кәрим Тинчуринның “Җилкәнсезләр” (яки “Американ”) комедиясендә сатирик типларның бирелеше.

## Билет №12

1. Габдулла Тукайның тормыш юлы, иҗаты. Шагыйрьнең балалар өчен язган әсәрләре: “Су анасы”, “Шүрәле” әкият-поэмалары, “Сабыйга”, “Эшкә өндәү”, “Эш беткәч уйнарга ярый” һ.б. шигырьләре.
2. Каюм Насыйриның “Әбугалисина” әсәрендә Әбугалисина һәм Әбелхарис образларына чагыштырма бәя бирегез.

## Билет №13

1. Әдәби әсәрдә тема, проблема, идея (мисаллар китереп аңлатырга). Портрет һәм пейзаж.
2. Фатих Кәримнең сугыш чоры әсәрләрендә сугыш темасының чагылышы (“Ант”, “ Ватаным өчен”, “Сөйләр сүзләр бик күп алар”, “Кыңгыраулы яшел гармун”, “Сибәли дә сибәли”, “Кайгы” һ.б.).

## Билет №14

1. Тел-сурәтләү чаралары: эпитет, метафора, чагыштыру, сынландыру, аллитерация һ.б. (мисаллар өстендә аңлатырга).
2. Әмирхан Еникинең “Әйтелмәгән васыять” повестенда Акъәби образына бәя бирегез. Васыять образы.

## Билет №15

1. Гомумтөрки әдәбият /М.Кашгарыйның “Диване лөгат әт-төрк”, Й.Баласагунлының “Котадгу белек” әсәрләре/.
2. Муса Җәлилнең “Моабит дәфтәрләре” циклында ирек һәм коллык темасы (“Җырларым”, “Кошчык”, “Тик булса иде ирек”, “Ышанма”, “Бер үгет” һ.б.). Бер шигырен яттан сөйләргә (укучы үзе сайлый).

## Билет №16

1. Суфичылык күренеше һәм суфичылык әдәбияты, аның төп

үзенчәлекләре.
2. Фатих Хөснинең “Йөзек кашы” повестенда Айдар һәм Госман образларына чагыштырма характеристика бирегез.

## Билет №17

1. XIX гасырның беренче яртысында татар әдәбияты.
2. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәрендә илаһи мәхәббәт темасының чагылышы.

## Билет №18

1. XIX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты. Әдәби хәрәкәттә барлыкка килгән үзгәрешләр, сүз сәнгатендәге төп яңалыклар.
2. Фатих Әмирханның “Нәҗип” хикәясендә Нәҗипнең эчке кичерешләрен аңлатып, уен һәм үч алу төшенчәләре ярдәмендә бәя бирегез.

## Билет №19

1. Татар халык авыз иҗаты, төп жанрлары. Җырларга, табышмакларга, мәкальләргә хас сыйфатлар.
2. Әмирхан Еникинең “Курай” (яки “Матурлык”) хикәсендә кеше күңеленең матурлыгы темасы.

## Билет №20

1. Татар халык авыз иҗатының төп жанрларынан берсе буларак әкиятләр, аларга  хас сыйфатлар.
2. Һади Такташның “Ак чәчәкләр” шигырендә анализ аша автор идеясен табыгыз.

## Билет №21

1. Баллада жанры, аның төп үзенчәлекләре (И. Юзеевның “Бакчачы турында баллада”, “Йолдыз Кашка турында баллада”лары).
2. Сәйф Сараиның “Гөлстан бит-төрки” әсәрендә шәфкатьлелек темасының чагылышы.

## Билет №22

1. Ризаэтдин Фәхретдиннең тормыш юлы һәм иҗаты. “Әсма, яки Гамәл вә җәза” романында гомумкешелек кыйммәтләренең чагылышы.
2. Әмирхан Еникинең “Курай” (яки “Матурлык”) хикәсендә курай моңы вазифасы.

## Билет №23

1. Муса Акъегетнең тормыш юлы, иҗаты. “ Хисаметдин менла” әсәрендә мәгърифәтчелек әдәбиятына хас үзенчәлекләр.
2. Габдулла Тукайның “Пар ат” шигырендә лирик герой кичерешләре, пар ат образына салынган мәгънә.

## Билет №24

1. Татар драматургиясенең формалашу тарихы һәм аның беренче адымнары, төп авторлар.
2. “Идегәй” дастанында конфликт үзенчәлеге һәм аның аша автор уздырган идея.

## Билет №25

1. Габделҗәббар Кандалыйның тормыш юлы һәм иҗаты. Татар поэзиясе үсешенә керткән өлеше.
2. Габдулла Тукайның “Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш” поэмасында Кисекбаш образы, аның аша шагыйрь уздырган фикер.

**Төзүчеләр**:
Филология фәннәре докторы, КФУ профессоры Д.Ф.Заһидуллина,
Филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты Н.М.Юсупова